УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.09.2024 Казан ш. № 01-05/242-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 18 августындагы 01-05/199-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машина йөртүче (тракторчы) таныклыгы бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү һәм элек чыгарылган норматив актларны федераль законнар таләпләренә туры китерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 18 августындагы 01-05/199-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машина йөртүче (тракторчы) таныклыгы бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган нигездә исәпкә алу бүлегенә әлеге боерыкны һәм кертелгән үзгәрешләре белән Административ регламент текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш.Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең боерыгы белән расланды
24.09.2024 № 01-05/242 пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 18 августындагы 01-05/199-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машина йөртүче (тракторчы) таныклыгы бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе) тарафыннан үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү барышында административ процедуралар һәм гамәлләр стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.»;

2 бүлектә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәте Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе тарафыннан Идарәнең территориаль бүлекләре аша күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша күрсәтелми.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) теоретик һәм гамәли имтихан тапшыру нәтиҗәләре буенча тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгы бирү;

2) теоретик һәм практик имтихан тапшыру нәтиҗәләре буенча тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгы бирүдән нигезле баш тарту;

3) теоретик һәм гамәли имтихан тапшыру нәтиҗәләре буенча үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына вакытлыча таныклык бирү;

4) тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгын алмаштыру;

2.3.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен түбәндәге ысуллар белән ала:

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә шәхсән барып;

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә (алга таба – «Интернет» челтәре) кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат - телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләрнең) бердәм порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) аша.

2.3.3. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә, Идарә бүлекләренә шәхсән бирелгән гариза турындагы белешмәләр, аны карау турында һәм карау нәтиҗәләре турында, үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә кертелгән затлар һәм транспорт чаралары белән идарә итү хокукыннан мәхрүм калган затлар турында, шулай ук бирелгән тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгы, аны алмаштыру яисә кире кайтару турындагы белешмәләр Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе тарафыннан тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасына яки, алга таба ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасына җибәрү юлы белән, «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелә.

2.4.1 пунктның икенче абзацында «10» саннарын «9» саны белән алмаштырырга;

2.6.1 пунктта егерме беренче һәм егерме икенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар

1) тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгын, шул исәптән югалган яисә яраксызга чыккан урынына үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына вакытлыча таныклык биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсеннән мәгълүмат;

2) транспорт чаралары белән идарә итү хокукыннан мәхрүм ителмәү турында белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсеннән);

3) Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсеннән Россия илкүләм машина йөртү таныклыгы турында мәгълүмат;

4) фамилияне, исемне, ата исемен (булган очракта) үзгәртүне раслый торган документлар (фамилияне, исемне яки ата исемен (булган очракта) үзгәртү факты булганда) – вәкаләтле органнардан;

5) индивидуаль исәп счетының (СНИЛС) иминият номеры турындагы белешмәләр (мөрәҗәгать итүче күрсәтмәгән очракта) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе тарафыннан, тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә соратып алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.»;

2.7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документлар исемлегендә күрсәтелгән бер яисә берничә документны тапшырмау тора.»

2.9 пунктның уникенче абзацында «КФҮ хезмәткәренең,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.11 пункттагы өченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.13 пунктта унсигезенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.13 пунктның унтугызынчы абзацында «, КФҮдә (хезмәт күрсәтү өчен гариза КФҮ аша бирелгән очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14.2 пунктның икенче абзацында «, һәм КФҮ аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14.2 пунктның өченче, бишенче һәм җиденче абзацында «һәм КФҮ аша» сүзләрен төшереп калдырырга.

2.14.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге мәгълүмат системалары кулланыла:

«Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы.».

3.3.1 пунктның өченче абзацында «КФҮдән» сүзләрен «белән» бәйлегече белән алмаштырырга;

3.4.1 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.2 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

5.1 пунктчаның беренче абзацында «дәүләт хезмәтен күрсәтүче КФҮ, КФҮ хезмәткәренең» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пунктчаның дүртенче һәм бишенче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

5.4 пунктчаның сигезенче абзацында «КФҮ, КФҮ хезмәткәренең» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктчаның өченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

5.4 пунктчаның дүртенче һәм бишенче абзацларында «КФҮ, КФҮ хезмәткәренең» сүзләрен төшереп калдырырга.